
# Татар әдәбияты
# 11 нче сыйныф

# Кәрим Тинчуринның тормыш һәм иҗат юлы.

- Тулы исеме:
- Кәрим Гали улы Тинчурин
- Туган көне:
- 1887 нче елның
- 15 нче сентябре
- Туган урыны:
- Пенза өлкәсе,
- Беднодемьянск районы,
- Белоозерка (Аккүл) авылы



# Бер – берсен тапкан ике йолдыз




1919 нчы елда Кәрим Тинчурин белән Заһидә Әхмәрова өйләнешәләр.
Зур туй ясап тормыйлар, авыр вакыт.

# Кәрим Тинчурин торган йорт

Хәзерге Профсоюз һәм М.Җәлил урамнары кисешкән урын.



# Кәрим Тинчурин күпкырлы талант иясе

Кәрим Тинчурин күпкырлы талант иясе булуы белән замандашларыннан аерылып тора. Ул – актер, режиссер, драматург буларак татар театрын ныгыткан сәнгатькәр, әмма шулар өстенә Кәрим Тинчурин проза остасы да, ул “Мәрҗәннәр” романы белән әдәбиятыбызның олы классигы булып тарихта калган зат...

Минтимер Шәймиев


# Сүнмәс йолдыз

- Милли драматургия үсеше тарихында Кәрим Тинчурин исеме кабатланмас урын алып тора. 1905 нче елгы революция дулкынында әдәбият һәм театр сәнгате мәйданына килеп, ул үзен талантлы драматург һәм актер, оста режиссёр һәм педагог итеп таныта, татар театрын үстерүгә һәм баетуга искиткеч зур көч куя.

# Иҗатташ дуслары
# Театр “йолдызлары”

- К.Тинчурин һәм
- Габдулла Кариев





- Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин

# “Зәңгәр шәл”нең төсе уңмас төсле, Кунмас төсле аңа тузаннар

- “Зәңгәр шәл”
- спектакленнән күренеш:
- Булат – Кәрим Тинчурин



# Сәхнәгә ул уйнар өчен түгел, Яшәр өчен менгән – яшәгән!

- К.Тинчурин таланты башка яклары белән дә ачыла бара: “Шомлы адым” “Соңгы сәлам”, “Беренче чәчәкләр”, “Назлы кияү” пьесаларын яза, аларны үзе үк режиссер буларак сәхнәгә куя, төп рольләрдә чыгыш ясый.

# Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы



# Партиянең әмере белән бит гел Үтәде ул хаклык кушканны

- Утызынчы еллар уртасында көчәеп киткән шәхес культы җилләре, К. Тинчурин кебек олуг шәхесне дә аяп узмады. Иҗатының һәм театрда эшчәнлегенең нәкъ чәчәк  аткан чорында – 50 яше тулган көннәрдә кулга алына.

# Кәрим Тинчуринны шушы кара капка аша 1937 нче елда алып чыгып китәләр



Саф күзләргә карап, мөмкин лә ул
“Халык дошманы” дип атарга

Л.Лерон


- Хаксызга “халык дошманы” , “милләтче” дип гаепләнеп, 1938 нче елның 15 нче ноябрендә судсыз-нисез атыла. Шәхес культы фаш ителгәннән соң, 1955 нче елда Г.Ибраһимов, Ш.Усманов, М.Галәү һ. б. сәяси корбаннар белән Кәрим Тинчурин шәхесе дә аклана, иҗаты халыкка кайтарыла.

**“Кәримнең үз гүре юк,шуңа күрә минем кабер ташыма аның исемен дә яздырырсыз. Минем гүрем Кәримнең гүре булыр.”**

Заһидә Тинчуринаның Рабит Батуллага васыяте.1988 нче ел



# “Чәчәкләрне шунда китерерсез”



# Берчак сүнгән йолдызларын Сүнмәс итеп кабат кабызган

- Бүген дә театрларыбызда К.Тинчурин тәрбияләгән артистларның шәкертләре эшли. Сәхнә йолдызлары аның әсәрләре аша зур чыныгу ала. Кәрим Тинчурин кабызган якты утлар буыннан-буынга күчерелә бара.